КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Республиканское агентство по печати
и массовым коммуникациям
Декабристов ул., 2, г.Казань, 420066

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ
Республика матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләр агентлыгы
Декабристлар ур., 2, Казан шәһәре, 420066

Тел.: (843)570-31-22, факс:(843)537-91-04, ra.tatmedia@tatar.ru, tatmedia.tatarstan.ru

ПРИКАЗ БОЕРЫК

«10» февраль 2021 ел. № 8-п

Социаль юнәлешле
коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан
күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының
билгеләнгән критерийларга туры килүе турында
бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ регламентын
раслау хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары нигезендә, шулай ук «Татарстан Республикасында социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар күрсәтә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирүне оештыру хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 22 августындагы 681 номерлы карарын үтәү максатларында боерык бирәм:

1. Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын расларга.

2. Әлеге Боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үземә алам.

Җитәкче А. С.Сәлимгәрәев

«Татмедиа» матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләр буенча республика
агентлыгының
2021 елның «10» 02
8 –п номерлы боерыгы белән расланды

# Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – Регламент) социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең тәртибен һәм стандартын билгели (алга таба – дәүләт хезмәте).

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр: Татарстан Республикасы территориясендә «Коммерциячел булмаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы $2^2$ пунктының 1 пунктчасында каралган түбәндәге иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтүче социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар (алга таба – социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар, коммерциячел булмаган оешмалар):

1) нәшерлек эшчәнлеген гамәлгә ашыру;

2) телепрограммалар эшләү һәм тарату;

3) радиопрограммалар эшләү һәм тарату.

1.3. Дәүләт хезмәте «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгы (алга таба – Агентлык) тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Агентлыкның урнашкан урыны: Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2 йорт.

Агентлыкның эш графигы: дүшәмбе – җомга көннәрендә 8.00 дән 17.00 гә кадәр, төшке аш 12.00 дән 13.00 гә кадәр, шимбә һәм якшәмбе ял көннәре.

Гаризалар кабул итү графигы: шимбә һәм якшәмбе көннәреннән тыш, Агентлыкның эш сәгатьләрендә һәр көнне.

Җәмәгать транспорты белән «Кәҗә бистәсе» метро станциясе» тукталышына кадәр килергә кирәк:

автобуслар №№ 15, 29, 30, 37, 75;

1 нче троллейбус.

Бинага керү өчен рөхсәтнамә яки шәхесне таныклый торган документ күрсәтергә кирәк.

1.3.2. Агентлыкның массакүләм мәгълүмат чаралары бүлеге (алга таба – ММЧ бүлеге) телефоны: (843) 570-31-12.

1.3.3. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба – «Интернет» челтәре) Агентлыкның рәсми сайты адресы: http://tatmedia.tatarstan.ru, электрон почта адресы: ra.tatmedia@tatar.ru

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүматны түбәндәгечә алырга мөмкин:

1) мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен дәүләт хезмәте турында Агентлык биналарында урнаштырылган визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат стендлары аша;

2) «Интернет» челтәре аша:

Агентлыкның рәсми сайтында (http://tatmedia.tatarstan.ru/);

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatarstan.ru);

Бердәй дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында (http://www.gosuslugi.ru)

3) Агентлыкка телдән мөрәҗәгать итеп (шәхсән килеп яисә телефон аша);

4) Агентлыкка язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать итеп.

1.3.5. Агентлыкның урнашу урыны, белешмә телефоннары, эш графигы, рәсми сайты адресы, шулай ук электрон почтасы турындагы мәгълүмат массакүләм мәгълүмат чаралары бүлеге белгече тарафыннан Агентлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында урнаштырыла.

Мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен Агентлык биналарындагы мәгълүмат стендларында һәм Агентлыкның рәсми сайтында урнаштырыла торган мәгълүмат дәүләт хезмәте турында әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3 - 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1. пунктларындагы (пунктчаларындагы) Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырылган белешмәне үз эченә ала.

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге (аларның реквизитларын һәм аларны рәсми бастырып чыгару чыганакларын күрсәтеп) Агентлыкның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган.

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

мөрәҗәгать итүче – дәүләт хезмәте күрсәтү турында телдән, язма яки электрон рәвештә мөрәҗәгать иткән социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешма (аларның вәкаләтле вәкилләре);

техник хата – Агентлык тарафыннан җибәрелгән һәм социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешма тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турындагы бәяләмәдә (алга таба – бәяләмә) күрсәтелгән белешмәләрнең хәбәрнамәдә күрсәтелгәннәргә туры килмәвенә йә бәяләмәне бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә җибәрүгә китергән хата (ялгыш язулар, басма хаталар, грамматик яки арифметик хаталар);

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыны – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль районы шәһәр (авыл) җирлегендә яисә шәһәр округында булдырылган территориаль яктан аерымланган структур бүлекчәсе (офисы).

Башка төшенчәләр һәм терминнар «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә кулланыла.

## 2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына таләпнең аталышы | Стандартка куелган таләпләрнең эчтәлеге | Хезмәт күрсәтүне яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең аталышы | Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү | «Татарстан Республикасында социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар күрсәтә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирүне оештыру хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 22 августындагы 681 номерлы карарының 2 пункты (алга таба – № 681 карар); Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 24 октябрендәге 902 номерлы карары белән расланган «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгы турында нигезләмәнең 3.3 пунктынданы 24 абзацы (алга таба – Агентлык турында Нигезләмә) |
| 2.2. Башкарма хакимият органының атамасы | «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгы | «Иҗтимагый файдалы хезмәтләр башкаручы коммерцияле булмаган оешмалар реестры |

| | | |
|---|---|---|
| | | турында» 2017 елның 26 гыйнварындагы 89 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешманы иҗтимагый файдалы хезмәтләр башкаручы дип тану турында карар кабул итү кагыйдәләре (алга таба– кагыйдәләр);<br>№ 681 карарның 2 пункты;<br>Агентлык турында Нигезләмәнең 3.3 пунктындагы 24 абзацы |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Кагыйдәләргә 2 нче кушымтада күрсәтелгән рәвештә бәяләмә йә әлеге Регламентка 2 нче кушымта нигезендә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә | Кагыйдәләрнең 5, 7, 8 пунктлары |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгы исәпкә алынган, срогы, әгәр Россия Федерациясе законнарында каралган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору срогы,<br>дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) срогы | Бәяләмә бирү турында гариза кергән көннән алып 19 эш көне эчендә.<br>Кагыйдәләрнең 6 пункты нигезендә Агентлык гарызнамәләр җибәргән очракта, күрсәтелгән вакыт озайтылырга мөмкин, әмма 15 эш көненнән дә озакка түгел.<br>Агентлык әлеге карарны кабул итү срогын озайту турында оешманың бәяләмә бирү хакындагы гаризасы кергән көннән алып биш эш көне эчендә гариза бирүчегә хәбәр итә.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү срогын туктатып тору Россия Федерациясе законнарында каралмаган.<br>Гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе булган документ мөрәҗәгать иткән көнне тапшырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документ гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын (почта аша, электрон адрес, факс буенча) кулланып, дәүләт хезмәте нәтиҗәсен рәсмиләштерү һәм теркәү көнендә җибәрелә. | Кагыйдәләрнең 6, 9 пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен һәм дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле булган мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, мөрәҗәгать итүченең аларны алу ысулы, шул исәптән электрон рәвештә, бу документларны тапшыру тәртибе | а) әлеге Регламентка 1 нче кушымтада бирелгән рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза);<br>б) гамәлгә кую документларының күчермәләре;<br>в) документлар мөрәҗәгать итүче исеменнән аның вәкиле тарафыннан тапшырылган очракта, мөрәҗәгать итүче вәкиле гамәлләр башкару өчен кирәкле һәм аның вәкаләтләрен таныклаучы ышанычнамәнең күчермәсе.<br>Мөрәҗәгать итүче шәхесне таныклый торган документ күрсәтергә тиеш.<br>Документларның күчермәләре, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә расланмаган очракта, оригиналларын күрсәтеп тапшырыла.<br>Мөрәҗәгать итүче оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтү сыйфатын бәяләүнең билгеләнгән критерийларына туры килүен нигезләүче документларны (белешмәләр, характеристика, эксперт бәяләмәләре, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары каршындагы Иҗтимагый советлар бәяләмәләре һәм башкалар) кушымта итеп тапшырырга мөмкин.<br>Мөрәҗәгать итүче тиешле иҗтимагый файдалы хезмәт буенча социаль хезмәт күрсәтүчеләр реестрына кертелгән очракта, мөрәҗәгать итүче күрсәтә торган хезмәтләрнең иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатын бәяләүнең билгеләнгән критерийларына туры килүен нигезләүче өстәмә документлар тапшыру таләп ителми | Кагыйдәләрнең 5 пункты |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган, дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында һәм дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары карамагындагы бүтән оешмаларда булган һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокукы булган | «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 44-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә төзелгән контрактларны үтәү кысаларында хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча оешманың гариза бирелгәнгә кадәрге ике ел дәвамында намуссыз башкаручылар (подрядчылар, башкаручылар) реестрында булмавын раслаучы документлар (белешмәләр) ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча (Монополиягә каршы федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе) алына. | Кагыйдәләрнең 6 пункты;<br>«Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү |

| | | |
|---|---|---|
| документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүченең аларны алу ысуллары, шул исәптән, электрон формада алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар саклана торган дәүләт органы, җирле үзидарә органы йә оешма | Мөрәҗәгать итүче әлеге пунктта күрсәтелгән белешмәләр булган документларны үз теләге белән тапшырырга, шул исәптән, мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә тапшырырга хокуклы.<br>Мөрәҗәгать итүче тарафыннан югарыда күрсәтелгән белешмәләрне үз эченә алган документларны тапшырмау, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүне тапшырмау өчен нигез булып тормый.<br>Мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:<br>дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшыруы каралмаган документларны һәм мәгълүматны яки башкару каралмаган гамәлләр башкаруны;<br>Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яки) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмалар карамагында булган, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр өчен түләү кертүне раслый торган документларны һәм мәгълүматны, моңа 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлешендә күрсәтелгән документлар керми;<br>№ 210-ФЗ Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны беренчел кабул итүдән баш тартканда яисә дәүләт хезмәте күрсәтүгә рөхсәт бирмәгәндә булу-булмавы һәм (яисә) дөреслеге күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүмат бирүне, моңа 210-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясындагы 4 өлешендә күрсәтелгән очраклар керми | турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары (алга таба – 880 номерлы карар) |
| 2.7. Дәүләт хезмәтен күрсәтергә рөхсәт бирү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләренең тулы исемлеге | 1) мөрәҗәгать итүче яисә аның вәкиле тарафыннан әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар тапшырылмаган;<br>2) әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелмәгән зат мөрәҗәгать итүче | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне | Бәяләмә бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора: | Кагыйдәләрнең 7 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| туктатып тору яисә аны күрсәтергә рөхсәт бирүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | а) иҗтимагый файдалы хезмәтнең аның эчтәлегенә карата Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләргә (күрсәтелә торган хезмәтнең күләме, сроклары, сыйфаты) туры килмәү;<br>б) иҗтимагый файдалы хезмәтне башкаруда турыдан-туры катнашучы затларның (шул исәптән оешма хезмәткәрләренең һәм гражданлык-хокукый характердагы килешүләр буенча җәлеп ителгән хезмәткәрләрнең) тиешле квалификациясе (шул исәптән һөнәри белеме, әлеге өлкәдә эш тәҗрибәсе) булмау, тиешле квалификациясе булган затлар саны җитмәү;<br>в) бәяләмә бирелү елына кадәрге ике ел дәвамында оешманың иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүгә бәйле гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм (яки) карарларына суд, дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль күзәтчелек органнары, компетенцияләре нигезендә башка дәүләт органнары тарафыннан нигезле дип танылган шикаятьләр булу;<br>г) оешма турындагы мәгълүматның ачыклыгы һәм һәркем алырлык булуы дәрәҗәсенең Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләргә (алар булса) туры килмәве;<br>д) бәяләмә бирелү елына кадәрге ике ел дәвамында 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән контрактларны үтәү кысаларында хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча намуссыз башкаручылар реестрында оешма турында мәгълүмат булу;<br>е) дөрес булмаган белешмәләр булган документлар яисә тиешенчә рәсмиләштерелмәгән документлар тапшыру.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр юк | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәткән өчен түләү күләмен алу тәртибе, күләме һәм нигезләре, әлеге түләүне исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан хезмәтләр күрсәтү турында гариза биргәндә һәм аның нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты | Мөрәҗәгать итүченең кабул итүне (аңа хезмәт күрсәтүне) көтү һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен алу вакыты максималь 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән | «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы Указының 1 пунктындагы «д» пунктчасы» |
| 2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан хезмәт күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең гаризасын теркәү срогы һәм тәртибе, шул исәптән электрон рәвештә | Гариза кергән көнне.<br>Әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән гариза һәм документлар почта аша яки электрон документ (документлар пакеты) рәвешендә җибәрелгән булса, Агентлыкның эш вакыты тәмамланганнан соң алынса, аларны алу көне булып киләсе эш көне санала.<br>Гариза бирү көне дип мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән барлык документлар тапшырган көн санала.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә кергән гариза ялдан (бәйрәмнән) соң килә торган эш көнендә теркәлә | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга, көтеп тору залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны тутыру урыннарына, тутыру үрнәкләре һәм һәр дәүләт хезмәтекүрсәтелү өчен кирәкле документлар исемлеге булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәтне күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиалы мәгълүматны урнаштыруга карата, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турындагы федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә күрсәтелгән объектлардан инвалидларның файдалана алуын тәэмин итүгә карата таләпләр | Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган Агентлык бинасында һәм бүлмәләрендә гамәлгә ашырыла.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиалы мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.<br>Бинаның, бүлмәләрнең һәм хезмәтләренң инвалидлар, шул исәптән кресло-коляскалардан һәм сукырларны йөртә торган этләрдән файдаланучы инвалидлар файдалана алырлык булуын тәэмин итү чаралары күрелә, шул исәптән:<br>бинага һәм бүлмәләргә тоткарлыксыз керү шартлары, шулай ук аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән файдалана алу мөмкинлеге;<br>Агентлык территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, Агентлык бинасына керү һәм чыгу, транспорт чарасына утырту һәм аннан төшерү, шул исәптән кресло-коляска кулланып, мөмкинлеге;<br>күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәтләнү функциясе бозылган инвалидларны озатып йөрү һәм аларга бинада һәм бүлмәләрдә ярдәм күрсәтү;<br>инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, биналарга, бүлмәләргә тоткарлыксыз үтеп керә алуын һәм хезмәт күрсәтүләрдән файдалана алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат чыганакларын тиешле урыннарда урнаштыру;<br>инвалидларга кирәкле авазлы һәм күрә торган мәгълүматны, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны рельефлы-ноктал Брайль шрифты белән башкарылган билгеләр ярдәмендә кабатлау, сурдотәрҗемәче һәм тифлосурдотәрҗемәче кертү;<br>«Озатып йөрүче этләрне махсус укытуны раслый торган документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган документ булган очракта, озатып йөрүче этнең бинага һәм бүлмәләргә керүен тәэмин итү; | «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон; 880 номерлы карар |

| | | |
|---|---|---|
| | хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләрнең инвалидларга башка затлар белән беррәттән каршылыксыз хезмәт күрсәтүдән файдалануына ярдәм итү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен уңайлылыгын тәэмин итү өлешендәге таләпләр 2016 елның 1 июленнән реконструкцияләнгән яки модернизация үткән объектларга карата кулланыла | |
| 2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану мөмкинлеге һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәткәндә вазыйфаи затлар белән аралашу саны һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмат-коммуникация технологияләрен кулланып, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (шул исәптән тулы күләмдә), мөрәҗәгать итүче сайлап алуы буенча (экстриториаль принцип) башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль бүлекчәсендә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15[1] статьясында каралган берничә дәүләт хезмәте һәм (яисә) | Дәүләт хезмәтеннән һәркем файдалана алу күрсәткечләренә түбәндәгеләр керә:<br>биналарның җәмәгать транспортына якын урында урнашуы;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар керү өчен уңайлы булуы;<br>белгечләрнең, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итә торган бүлмәләрнең җитәрлек санда булуы;<br>мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Агентлыкның рәсми сайтында, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу;<br>гаризаны электрон рәвештә бирү мөмкинлеге;<br>мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәтләрен күрсәтү нәтиҗәләрен электрон рәвештә алу мөмкинлеге;<br>инвалидларга башка затлар белән беррәттән хезмәт күрсәтүгә комачаулый торган, бинага үтеп керә алуга бәйле булмаган каршылыкларны булдырмау.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:<br>документларны кабул итү һәм карау срокларын үтәү;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тапшыру срогын үтәү;<br>Агентлык белгечләре тарафыннан әлеге Регламентны бозуга карата прецедентларның (нигезләнгән шикаятьләрнең) булмавы.<br>Мөрәҗәгать итүченең Агентлык белгечләре белән хезмәттәшлеге саны:<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны тапшырганда – бердән дә артмый (консультацияләрне исәпкә алмыйча); | |

| | | |
|---|---|---|
| муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза бирү юлы белән дәүләт хезмәтеннән файдалана алу мөмкинлеге йә мөмкин булмавы. | дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша җибәргәндә – юк (консультацияләрне исәпкә алмыйча).<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең Агентлык белгече белән бер хезмәттәшлеге 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү, дәүләт хезмәтен күрсәтүгә гариза бирүне дә кертеп, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыны аша башкарылмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Агентлыкның рәсми сайтында, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында алынырга мөмкин.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы гариза буенча башкарылмый | |
| 2.16. Башка таләпләр, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган таләпләр | Гариза һәм документлар (документлар күчермәләре) Агентлыкка «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) һәм 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланган электрон документлар рәвешендә җибәрелергә мөмкин | 63-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>210-ФЗ номерлы Федераль закон |

### 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү сроклары, аларны башкару тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелеген тасвирлау.

3.1.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә консультация бирү һәм ярдәм күрсәтү;

2) гаризаны һәм кушып бирелгән документларны иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәяләү буенча кабул итү һәм теркәү;

3) дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара гарызнамәләр әзерләү һәм җибәрү;

4) бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә проектын әзерләү;

5) мөрәҗәгать итүчегә бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә бирү;

6) техник хаталарны төзәтү.

3.2. Мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү, мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә, ярдәм күрсәтү.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында консультация алу өчен массакүләм мәгълүмат чаралары бүлегенә шәхсән, телефон һәм (яки) почта аша (шул исәптән электрон) мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Массакүләм мәгълүмат чаралары бүлеге белгече мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен гаризаның рәвеше һәм башка мәсьәләләр буенча консультация бирә. Кирәк булганда, массакүләм мәгълүмат чаралары бүлеге белгече мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә, ярдәм итә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура, мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә, мөрәҗәгатьләрнең электрон формада ял (бәйрәм) көнендә килү очракларыннан тыш, гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: тапшырылган документларның составы, рәвеше һәм эчтәлеге буенча консультация, искәрмәләр, мөрәҗәгать итүчегә, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны тутыру өлешен дә кертеп, ярдәм итү, гражданнар мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында консультация бирү (мөрәҗәгать итүчегә ярдәм итү) турында язма.

3.3. Гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү.

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче үзе (аның вәкиле) әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны (документларның күчермәләрен) кушып, Агентлыкның Гомуми бүлегенә (алга таба – Гомуми бүлек) әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында күрсәтелгән рәвештә гариза бирә.

Гариза һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә расланган аңа кушып бирелә торган документларның күчермәләре, шәхесен таныклаучы документның күчермәләреннән тыш, җибәрү фактын һәм датасын расларга мөмкинлек бирүче

ысул белән почта аша җибәрелергә мөмкин.

Гариза һәм 63-ФЗ номерлы Федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә имзаланган (расланган) электрон документлар рәвешендәге документларның күчермәләре Агентлыкка мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон чыганакларны һәм (яки) гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрен кулланып тапшырылырга мөмкин, моңа «Интернет» челтәре дә керә.

Гариза шулай ук Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша да бирелергә мөмкин.

Почта аша яки электрон рәвештә бирелгән гариза гомуми тәртиптә карала.

3.3.2. Гомуми бүлек белгече түбәндәгеләрне башкара:

дәүләт хезмәте алучының законлы вәкиле яисә вәкаләтле заты буларак эш итүче мөрәҗәгать итүченең вәкаләтләрен тикшерү;

әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларның булуын һәм аларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерү. Тикшерү массакүләм мәгълүмат чаралары бүлеге белгече катнашында гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүче үзе мөрәҗәгать иткәндә документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7 пунктында каралган нигезләр булган очракта, белгеч мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тарту өчен нигезләр булуы турында хәбәр итә һәм аңа, сәбәбен аңлатып, документларны кире кайтара. Мөрәҗәгать итүче таләбе буенча баш тарту язма рәвештә рәсмиләштерелә.

Мөрәҗәгать итүче гаризаны һәм документларны почта (электрон почта) аша җибәргәндә, Гомуми бүлек белгече аңа, баш тарту өчен нигезләрнең эчтәлеген язмача аңлатып, документларны почта (электрон почта) аша кире кайтара.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, Гомуми бүлек белгече түбәндәгеләрне башкара:

гаризаны кабул итү һәм теркәү;

гариза бирүчегә почта аша яисә электрон почта аша (аның теләге буенча) номер куелган, кабул итү датасы һәм вакыты күрсәтелгән гаризаның күчермәсен тапшыру;

Гаризаны «Электрон Хөкүмәт» Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасы (алга таба – электрон документ әйләнеше) аша электрон рәвештә Агентлык җитәкчесенә (алга таба – җитәкче) юллау.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура, гариза һәм документлар кергән көнне, ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә гариза керү очракларыннан тыш, гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм кушып бирелгән документлар белән бергә җитәкчегә җибәрелгән гариза.

3.3.3. Җитәкче гаризаны карый һәм карау өчен җитәкче урынбасарына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура гариза теркәлгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: карау өчен җитәкче урынбасарына җибәрелгән гариза.

3.3.4. Җитәкче урынбасары гаризаны карый һәм карау өчен Агентлыкның массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү идарәсе башлыгына (алга таба – Идарә башлыгы) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура гариза теркәлгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: карау өчен Идарә башлыгына җибәрелгән гариза.

3.3.5. Идарә башлыгы җаваплы башкаручыны (алга таба – массакүләм мәгълүмат чаралары бүлеге белгече) билгеләп куя һәм аңа башкару өчен гаризаны тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура гаризаны теркәгәннән соң бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: үтәү өчен массакүләм мәгълүмат чаралары бүлеге белгеченә җибәрелгән гариза.

3.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара гарызнамәләр төзү һәм җибәрү.

3.4.1. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документлар (белешмәләр) тапшырылмаганда, массакүләм мәгълүмат чаралары бүлеге белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек ярдәмендә электрон рәвештә, оешма бәяләмә бирелү елына кадәрге ике ел дәвамында 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән контрактларны үтәү кысаларында хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча намуссыз башкаручылар (подрядчиклар, үтәүчеләр) реестрында булмавын раслаучы документлар җибәрүне сорап гарызнамә җибәрә (Монополиягә каршы федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе);

Ведомствоара гарызнамә электрон имза куелган электрон документ рәвешендә, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы (алга таба – СМЭВ) каналлары буенча әзерләнә һәм җибәрелә.

СМЭВ каналлары буенча ведомствоара гарызнамә әзерләү һәм җибәрү техник яктан мөмкин булмаганда, ведомствоара гарызнамә кәгазь чыганакларда почта аша яки, почта элемтәсе һәм курьер аша кабатлап, факс буенча җибәрелә.

Ведомствоара гарызнамә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7.2 статьясы таләпләре нигезендә әзерләнә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура гариза массакүләм мәгълүмат чаралары бүлеге белгеченә кергән көннән алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: ведомствоара гарызнамә әзерләү һәм җибәрү.

3.4.2. Ведомствоара хезмәттәшлек органнары белгечләре соратып алына торган документларны (белешмәләрне) әлеге Регламентның 3.4.1 пунктында күрсәтелгән, СМЭВ аша кергән гарызнамә нигезендә законнарда билгеләнгән срокта тапшыралар.

Процедураларның нәтиҗәсе: гарызнамәгә җавап буларак алынган документлар (белешмәләр) йә соралган мәгълүматларның булмавы турында Агентлыкка җибәрелгән хәбәрнамә.

3.4.3. Агентлыкка бәяләмә бирү турында гариза кергән очракта һәм шул ук вакытта 681 номерлы карар нигезендә иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтү сыйфатын бәяләү берничә башкарма хакимият органы, шул исәптән Агентлык тарафыннан гамәлгә ашырыла, бәяләмә Агентлык тарафыннан бирелә. Агентлык,

кирәк булганда, кызыксынучы башка органнардан, шулай ук дәүләт хакимиятенең башка органнарыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә белешмәләр соратып ала.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура гариза массакүләм мәгълүмат чаралары бүлеге белгеченә кергән көннән алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: гарызнамәләр әзерләү һәм җибәрү, дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм аларның карамагындагы башка оешмалардан ведомствоара гарызнамәгә җавап буларак документлар (белешмәләр) алу.

3.5. Бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә бирү турында карар әзерләү һәм кабул итү.

3.5.1. Массакүләм мәгълүмат чаралары бүлеге белгече әлеге Регламентның 3.4.1 – 3.4.3 пунктларында күрсәтелгән документлар (белешмәләр) нигезендә:

гариза һәм мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларны карый;

хат, бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә проектын әзерли һәм аларны килештерү өчен Идарә башлыгына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар гарызнамәләргә җаваплар алынган көннән сигез эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: килештерү өчен Идарә башлыгына җибәрелгән хат, бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә проекты.

3.5.2. Идарә башлыгы хат, бәяләмәне яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә проектын тикшерә һәм килештерү өчен аларны Җитәкче урынбасарына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура күрсәтелгән проектлар килештерү өчен Идарә башлыгына кергән мизгелдән алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: хат, бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә проектын килештерү өчен Җитәкче урынбасарына җибәрү.

3.5.3. Җитәкче урынбасары хат, бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә проектларын килештерә һәм аларның Җитәкчегә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура әлеге проектлар килештерү өчен Җитәкчегә кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: килештерелгән һәм җитәкчегә карап тикшерү өчен җибәрелгән хат, бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә проектлары.

3.5.4. Җитәкче хатка, бәяләмәгә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәгә кул куя һәм аларны массакүләм мәгълүмат чаралары бүлегенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура күрсәтелгән проектлар килештерү өчен Җитәкчегә кергән мизгелдән алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Җитәкче имзалаган һәм ММЧ бүлегенә җибәрелгән хат, бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә.

3.5.5. Массакүләм мәгълүмат чаралары бүлеге белгече:

гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе турында хәбәр итә, хатны, бәяләмәне, бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәне теркәү өчен Гомуми бүлеккә тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар Җитәкче хатны, бәяләмәне яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәне имзалаган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: хатны, бәяләмәне яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәне теркәү өчен Гомуми бүлеккә җибәрү.

3.6. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсен юллау.

3.6.1. Гомуми бүлек белгече:

хатны, бәяләмәне яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә кәгазен терки һәм аны гаризада күрсәтелгән ысул белән мөрәҗәгать итүчегә җибәрә (тапшыра).

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура түбәндәге вакыт эчендә башкарыла:

бәяләмәне яки бәяләмәне бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәне почта аша җибәргәндә – бәяләмә яки бәяләмәне бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәне җитәкче имзалаган көннән соң бер эш көне эчендә;

гаризада бәяләмәне яки бәяләмәне бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәне шәхси үзенә тапшыру турында күрсәтелгәндә – мөрәҗәгать итү көнендә.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгән (бирелгән) хат, бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә.

3.7. Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең рәсми порталы аша кергән гаризаны карап тикшерү.

Интернет-кабул итү бүлмәсе аша кергән гариза әлеге Регламентның 3.3-3.6 пунктларында каралган тәртиптә теркәлә һәм карала.

3.8. Техник хаталарны төзәтү.

Бәяләмәне яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәне яңадан рәсмиләштерү элек бирелгән бәяләмәдә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәдә җибәрелгән техник хаталарны (ялгыш язуларны, басма хаталарны, грамматик яки арифметик хаталарны) төзәтүгә бәйле рәвештә башкарыла.

Бәяләмәне йә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәне яңадан рәсмиләштерү әлеге Регламентның 3.3.1 пунктында күрсәтелгән ысулларның берсе буенча тапшырылган теркәлгән гариза нигезендә гамәлгә ашырыла, (гаризаның тәкъдим ителә торган рәвеше әлеге Регламентның 3 нче кушымтасында күрсәтелгән). Гаризага мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хатасы булган бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә, шулай ук, документлар мөрәҗәгать итүче вәкиле тарафыннан тапшырылса, мөрәҗәгать итүче исеменнән гамәлләр башкару өчен кирәкле булган һәм гариза бирүче вәкил вәкаләтләрен раслаучы ышанычнамә кушымта итеп бирелә.

3.8.1. Гомуми бүлек белгече:

техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итү һәм электрон документ әйләнешендә теркәү;

Җитәкчегә электрон документ әйләнеше аша электрон рәвештә гариза юллау.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура гариза кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм Җитәкчегә җибәрелгән гариза.

3.8.2. Җитәкче гаризаны карый һәм карау өчен Җитәкче урынбасарына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура гариза теркәлгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: тикшерү өчен Җитәкче урынбасарына җибәрелгән гариза.

3.8.3. Җитәкче урынбасары гаризаны карый һәм карау өчен Идарә башлыгына юллый.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура гариза теркәлгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: карау өчен Идарә башлыгына җибәрелгән гариза.

3.8.4. Идарә башлыгы башкару өчен массакүләм мәгълүмат чаралары бүлеге белгечен билгели һәм гаризаны аңа тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура Идарә башлыгына гариза җибәрелгәннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: башкару өчен массакүләм мәгълүмат чаралары бүлеге белгеченә җибәрелгән гариза.

3.8.5. Массакүләм мәгълүмат чаралары бүлеге белгече:

хат, яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә проектын әзерли һәм килештерү өчен аларны Идарә башлыгына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар гариза башкару өчен массакүләм мәгълүмат чаралары бүлеге белгеченә җибәрелгәннән соң ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: килештерү өчен Идарә башлыгына җибәрелгән хат, яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә проекты.

3.8.6. Идарә башлыгы әзерләнгән хатның, яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә проектының дөреслеген тикшерә, аны килештерә һәм килештерү өчен Җитәкче урынбасарына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура хат, яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә проекты килештерү өчен массакүләм мәгълүмат чаралары бүлеге белгеченнән килгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Идарә башлыгы тарафыннан килештерелгән һәм килештерү өчен Җитәкче урынбасарына юлланган хат, яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә проекты.

3.8.7. Җитәкче урынбасары хатны, яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә проектын килештерә һәм аларны Җитәкчегә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура хат, яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә проекты Идарә башлыгыннан җибәрелгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Җитәкче урынбасары белән килештерелгән һәм карау өчен Җитәкчегә җибәрелгән хат, яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә проекты.

3.8.8. Җитәкче хатка, яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмәгә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәгә кул куя һәм аларны массакүләм мәгълүмат чаралары бүлегенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура күрсәтелгән проектлар килештерү өчен Җитәкчегә кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Җитәкче тарафыннан имзаланган һәм массакүләм мәгълүмат чаралары бүлегенә җибәрелгән хат, яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә.

3.8.9. Массакүләм мәгълүмат чаралары бүлеге белгече:

мөрәҗәгать итүчегә, техник хатаны төзәтү турындагы гаризада яки дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып, документның әзерлеге турында хәбәр итә, хатны, яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмәне яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәне теркәү өчен гомуми бүлеккә тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар Җитәкче хатны, яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмәне яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәне имзалаган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Гомуми бүлеккә теркәлүгә тапшырылган хат, яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә.

3.8.10. Гомуми бүлек белгече:

хатны, яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмәне яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәне терки һәм аны гаризада күрсәтелгән ысул белән мөрәҗәгать итүчегә җибәрә (бирә).

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура түбәндәге вакыт эчендә башкарыла:

бәяләмәне яки бәяләмәне бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәне почта аша җибәргәндә – хатны, бәяләмә яки бәяләмәне бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәне җитәкче имзалаган көннән соң бер эш көне эчендә;

гаризада бәяләмәне яки бәяләмәне бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәне шәхси үзенә тапшыру турында күрсәтелгәндә – мөрәҗәгать итү көнендә.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгән (бирелгән) хат, яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм рәвешләре

4.1. Агентлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан әлеге Регламент нигезләмәләрен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләрне билгели торган башка норматив хокукый актларны үтәүгә, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул итүгә агымдагы контроль тиешле административ процедураны үтәү өчен җаваплы зат һәм дәүләт хезмәте күрсәтү эшен оештыру өчен җаваплы җитәкче урынбасары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.2. Агымдагы контроль Агентлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан әлеге Регламент нигезләмәләрен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләрне билгеләүче башка норматив хокукый актларны үтәүне һәм башкаруны тикшерү юлы белән гамәлгә ашырыла.

Агымдагы контроль даими нигездә башкарыла.

4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту Агентлыкның дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белән язылган мөрәҗәгатьләрне тикшерүне, алар буенча карарлар кабул итүне һәм аларга җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту рәвеше түбәндәге тикшерүләрне үткәрүдән гыйбарәт:

- эш башкару бүлеген;
- документларны карау нәтиҗәләренең законнарга (әлеге Регламент) таләпләренә туры килүен;
- документларны кабул итү срокларын һәм тәртибен үтәүне;
- дәүләт хезмәте күрсәткәндә нәтиҗәләрне бирү срокларын һәм тәртибен үтәүне.

Тикшерүләр уздыруның ешлыгы алдан планлаштырылырга (эш планнары нигезендә) һәм планнан тыш (мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча) булырга мөмкин.

4.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын планнан тыш тикшерү үткәрү турындагы карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) элегрәк ачыкланган, дәүләт хезмәтен күрсәтүгә таләпләрне билгели торган Регламент һәм башка норматив хокукый актлар таләпләрен бозуларны бетерүне тикшерүгә бәйле рәвештә;

2) Агентлыкның дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи затларының гамәлләре (гамәл кылмаулары) юридик затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга китерүе турында мөрәҗәгате.

4.5. Үткәрелгән тикшерү нәтиҗәсе буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу ачыкланган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен җаваплы булган, гаепле дип танылган вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.6. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалар ягыннан дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту Агентлык эшчәнлегенең ачыклыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм ышанычлы мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау юлы белән гамәлгә ашырыла.

## 5. Агентлык, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьне судка кадәр (судтан тыш) хәл итү тәртибе

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр Агентлык, Агентлыкның вазыйфаи заты, яисә Агентлыкның дәүләт граждан хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьне судка кадәр хәл итү өчен Агентлыкка бирергә хокуклы.

Дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә җитәкче тарафыннан кабул ителгән карарларга, гамәлләргә (гамәл кылмауга) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелә.

5.2. Мөрәҗәгать итүче шикаять белән, шул исәптән түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гаризаны теркәү вакыты бозылу;

2) дәүләт хезмәтен күрсәтүнең билгеләнгән вакыты бозылу;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында күрсәтелмәгән документлар яисә мәгълүмат сорау, гамәлләр башкаруны таләп итү;

4) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуның нигезләре федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп итү;

7) Агентлыкның, аның вазыйфаи затының дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы йә мондый төзәтмәләрнең билгеләнгән срогы бозылу;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срогы яисә тәртибе бозылу;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торуның нигезләре федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының законнарында һәм башка норматив хокукый актларында каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору;

10) 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документларны кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканда, йә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда

юклыгы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны таләп итү.

5.3. Шикаять кәгазь чыганакта яки электрон рәвештә язмача бирелә.

Агентлыкның, Агентлыкның вазыйфаи затының, Агентлыкның дәүләт хезмәткәренең, җитәкченең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять почта аша, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша, «Интернет» челтәрен кулланып, Агентлыкның рәсми сайты, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы аша җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхси кабул иткәндә алынырга мөмкин.

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

1) Агентлыкның, Агентлыкның вазыйфаи затының яисә карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелә торган дәүләт граждан хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), физик затның яшәү урыны турында мәгълүматлар, юридик затның урнашу урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиешле электрон почта адресы (булган очракта) һәм почта адресы;

3) Агентлыкның, аның вазыйфаи затының яисә дәүләт граждан хезмәткәренең шикаять бирелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

4) Агентлыкның, аның вазыйфаи затының яисә дәүләт граждан хезмәткәренең карары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән мөрәҗәгать итүченең килешмәве дәлилләре.

5.5. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан аның дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яисә аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.6. Шикаятьне тикшерү срогы – ул теркәлгәннән соң 15 эш көне эчендә. Агентлык, Агентлыкның вазыйфаи заты мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән йә җибәрелгән хаталарны төзәтүдән баш тарткан очракта йә шундый хаталарны төзәтүнең билгеләнгән срогы бозылганда – теркәлгән көннән биш эш көне эчендә.

5.7. Шикаятьне тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән алу каралмаган акчаларны кире кайтару рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннең икенче көненнән дә соңга калмыйча, шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында мөрәҗәгать итүчегә язмача һәм мөрәҗәгать итүченең теләге буенча электрон рәвештә дәлилләнгән җавап җибәрелә.

5.7.1. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, мөрәҗәгать

итүчегә дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатларында Агентлык тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенәләр һәм дәүләт хезмәте күрсәтү максатларында мөрәҗәгать итүчегә киләчәк гамәлләр турында мәгълүмат бирәләр.

5.7.2. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип табылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә юллана торган җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга карата шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.8. Шикаятьне тикшерү барышында яисә тикшерү нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу составы яки җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне тикшерү буенча вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
1 нче кушымта

(тәкъдим ителә торган рәвеше)

«Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгы җитәкчесе

__________________________________
(фамилия, инициаллар)

__________________________________

__________________________________
(оешманың исеме, адресы (почта һәм (яки) электрон), телефон номеры (булган очракта)

ГАРИЗА

__________________________________________________________________
(социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешма исеме)
социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешма тарафыннан күрсәтелә торган

__________________________________________________________________
(иҗтимагый файдалы хезмәт атамасы)
иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең сыйфаты билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмә бирүегезне сорыйм.

Оешма чит ил агенты функциясен үтәүче коммерциячел булмаган оешма түгел, бер ел дәвамында әлеге иҗтимагый файдалы хезмәтләрне күрсәтә, аларның сыйфаты «Иҗтимагый файдалы хезмәтләр исемлеген һәм аларны күрсәтүнең сыйфатын бәяләү критерийларын раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 27 октябрендәге 1096 номерлы карары белән расланган бәяләү критерийларына туры килә:

__________________________________________________________________

__________________________________________________________________

__________________________________________________________________
(иҗтимагый файдалы хезмәтнең аның эчтәлегенә (күләменә, срокларына, сыйфатына) карата Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары белән билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслау.

___

(иҗтимагый файдалы хезмәтне башкаруда турыдан-туры катнашкан, тиешле квалификацияле (шул исәптән һөнәри белем, тәҗрибә, тиешле өлкәдә эшләү) затларның (шул исәптән оешма хезмәткәрләре һәм граждан-хокукый характердагы шартнамәләр буенча җәлеп ителгән хезмәткәрләр) булуын, мондый затларның җитәрлек санда булуын раслау)

___

___

___

___

(иҗтимагый файдалы хезмәтләрдән файдаланучыларның аларны күрсәтү сыйфатыннан канәгать булуын раслау (бәяләмә бирелү елына кадәрге ике ел дәвамында оешманың иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүгә бәйле гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм (яки) карарларына суд, дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль күзәтчелек органнары, компетенцияләре нигезендә башка дәүләт органнары тарафыннан нигезле дип танылган шикаятьләр булмауны раслау)

___

(коммерциячел булмаган оешма турында мәгълүматның ачыклыгын һәм һәркем файдалана алырлык булуын раслау)

___

(бәяләмә бирелү елына кадәрге ике ел дәвамында 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән контрактларны үтәү кысаларында хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча намуссыз башкаручылар реестрында оешма турында мәгълүмат булмауны раслау)

Раслау документлары:
1. ___
2. ___
3. ___

һәм башкалар.

___

(Вазыйфасы) (Имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме)

«____» ____________20_ел

М. у. (булганда)

Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
2 нче кушымта

(тәкъдим ителә торган рәвеше)

Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешма тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә

«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәяләү нәтиҗәләре буенча:

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

(тулы исеме һәм төп дәүләт теркәү номеры
социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешма)

социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешма тарафыннан күрсәтелә торган:

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

(иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең атамасы)

сыйфатының билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә бирүдән баш тарта.

Күрсәтелгән иҗтимагый файдалы хезмәтләр иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәяләүнең билгеләнгән критерийларына түбәндәге нигезләрдә туры килми:

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

(критерийларга туры килмәү күрсәтелә)

Җитәкче _______________ __________________ ___________________________

М. у. (дата) (имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
3 нче кушымта

(тәкъдим ителә торган рәвеше)

____________________________________
(дәүләт хезмәте күрсәтүче орган исеме,
______________________________________

______________________________________
________________________________
оешманың исеме, адресы (почта һәм (яки) электрон), телефон номеры (булганда)

Техник хаталарны төзәтү турында
гариза

Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар күрсәтә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмә биргәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм.

Бирелгән документта_________________________________________________________
(бирелгән документ)
________________________________________________________________________________
_______________________________________________________________дип күрсәтелгән

Дөрес мәгълүмат:____________________________________________________
________________________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүегезне һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләр кертүегезне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.

2.

Документның әзерлеге турында мине хәбәр итүегезне сорыйм

______________________________________________________________________________
(хәбәр итү ысулы)

_______________________________________________ _____________________
(дата) (гариза бирүче/вәкил имзасы) (фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Социаль юнәлешле коммерцияле
булмаган оешмалар тарафыннан
күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы
хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән
критерийларга туры килүе турында
бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ
регламентына
кушымта (белешмә)

## Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә җаваплы һәм аны гамәлгә ашыруны тикшереп торучы вазыйфаи затларның реквизитлары

«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы

| Вазифасы | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Җитәкче | (843) 570-31-22 | ra.tatmedia@tatar.ru |
| Җитәкче урынбасары | (843) 570-31-02 | Id.Mirgalimov@tatar.ru |
| Массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү идарәсе башлыгы | (843) 570-31-12 | A.Bakunina@tatar.ru |
| Массакүләм мәгълүмат чаралары бүлеге баш белгече | (843) 570-31-12 | Leniza.Alimbekova@tatar.ru |
| Гомуми бүлек башлыгы | (843) 570-31-23 | Tatyana.Kazachenko@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

| Адресы | Вазыйфасы | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|---|
| 420014, Казан шәһәре, Ирек мәйданы, 1 | Татарстан Республикасы халыклары мәдәниятен һәм телләрен үстерү идарәсе башлыгы | (843) 264-76-19 | Lyaysan.Nizamova@tatar.ru |